КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 21 февраль г.Казань № 125

2020 – 2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан халыкның тормыш сыйфатын бәяләү һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Декабрга теркәлгәннәрне расларга:

2020 – 2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан халыкның тормыш сыйфатын бәяләү һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсе (алга таба – Дәүләт йөкләмәсе);

дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) төбәк төрләре буенча тиешле эшчәнлек өлкәсендә закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерүне минимальләштерүдә чагылдырылган «А» төркеменә керә торган контроль-күзәтчелек эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләре исемлеге.

2. Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Дәүләт йөкләмәсе нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән берлектә «Ачык Татарстан» мәгълүмат порталының «Ведомстволарның хисаплары» бердәм дәүләт хисап системасында (алга таба – Система) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының хисап формаларына үзгәрешләр кертүне;

тәэмин итәргә:

статистик мәгълүматларның фактик мәгънәләрен Системага кертү һәм аларны актуаль хәлдә тоту;

Дәүләт биреме үтәлешенең квартал саен мониторингы.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына, Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләренә:

Дәүләт йөкләмәсе индикаторларының факттагы күрсәткечләрен кертүне һәм Системада хисапларны бастыруны тәэмин итәргә:

квартал саен индикаторлар буенча – хисап кварталыннан соң килүче айның 18 числосына кадәр һәм IV квартал индикаторлары буенча – 25 гыйнварга кадәр;

еллык индикаторлар буенча – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган сроклар нигезендә;

агымдагы елның 1 декабренә кадәр планлаштырылган өч елга Дәүләт йөкләмәсен формалаштыру максатларында теркәлгән индикаторлар буенча агымдагы ел күрсәткечләрен һәм өч елга планлаштырылган күрсәткечләрне бәяләүне Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка башкарма органнары өчен Индикаторны исәпләүче һәм системага мәгънәләр кертүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына хисап кварталыннан соң килүче айның 16 числосына кадәр һәм 23 гыйнварга кадәр – IV квартал индикаторлары буенча системада дәүләт заданиесенең квартал индикаторларының факттагы күрсәткечләрен кертүне тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләренә әлеге Системадагы мәгълүматларны актуальләштерергә кирәк булганда регламент срогы үткәннән соң бу хакта Тарстан Рреспубликасының социаль-икътисадый мониторинг буенча комитетына һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына хәбәр итәргә.

6. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) функцияләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына:

2020 елның 30 апреленә кадәр «А» төркеменә керүче контроль-күзәтчелек эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләре паспортларын расларга;

ел саен, 1 декабрьгә кадәр, «А» төркеменә керүче контроль-күзәтчелек эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләре паспортларын актуальләштерүне тәэмин итәргә;

квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 30 числосына кадәр, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениесенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында аларның үтәлешен мониторинглау нигезендә контрольнең (күзәтчелекнең) төбәк төрен гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге һәм файдалылыгының квартал саен күрсәткечләренә ирешү йомгаклары турында мәгълүмат урнаштырырга.

7. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына:

хисап елына индикаторларның чик күрсәткечләрен Системага кертүне һәм аларны ел дәвамында актуальләштерүне тәэмин итәргә;

квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 20 числосына кадәр һәм IV квартал индикаторлары буенча – 30 гыйнварга кадәр Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан квартал күрсәткечләрен үтәү мониторингы нигезендә

квартал күрсәтечләренә ирешү йомгаклары турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырырга;

ел саен, 1 апрельгә кадәр, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышында карап тикшерү өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан узган ел өчен дәүләт йөкләмәсен үтәү нәтиҗәләре турында аны үтәү мониторингы нигезендә үтәү йомгаклары турында мәгълүмат бирергә.

8. Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына Системадагы мәгълүматларны автоматик режимда чагылдырырга.

9. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

индикаторларның үтәлешен бәяләү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләреннән чыгып эшчәнлек нәтиҗәлелеге индикаторларының иң яхшы күрсәткечләренә ирешүне стимуллаштыру максатларында Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарын, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләрен стимуллаштыру турында карар кабул итәргә хокуклы;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләренең Дәүләт йөкләмәсен үтәү процентын санау максатларында алар тарафыннан барлык индикаторлар күрсәткечләренә ирешү буенча квартал рейтингын формалаштырганда индикаторларның авырлыгы тигез дип санала;

еллык күрсәткечләрнең гамәлдәге әһәмияте хисап чорыннан соң килүче икенче квартал мәгълүматларын бәяләгәндә исәпкә алына.

10. Хисап бастырылу датасына Дәүләт йөкләмәсе индикаторлары буенча статистик мәгълүматлар булмаган очракта хисап формасына Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы бәяләве буенча мәгълүматлар кертелә һәм киләсе хисап чорында фактик күрсәткечләр кертелә.

11. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына бер ай эчендә дәүләт программаларына индикаторлары мәгънәләрен Дәүләт биреме индикаторлары мәгънәсенә туры китерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр тапшырырга.

12. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«2019 – 2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләренә халыкның тормыш сыйфатын бәяләү һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен раслау турында» 2018 ел, 27 декабрь, 1244 нче;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләренә халыкның тормыш сыйфатын бәяләү һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен раслау турында» 2018 ел, 27 декабрь, 1244 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 ел, 17 октябрь, 913 нче;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләренә халыкның тормыш сыйфатын бәяләү һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен раслау турында» 2018 ел, 27 декабрь, 1244 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 ел, 30 декабрь, 1251 нче.

13. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин